ГЛАВА
Салаушского сельского поселения
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Салагыш авыл җирлеге
БАШЛЫГЫ

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

18.10.2019 Салагыш авылы № 3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Салагыш авылында халыкның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирлеүзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» 2004 нче елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге башлыгы
к а р а р б и р д е:

1. 2019 нчы елның 31 октябрендә Салагыш авыл клубы бинасында халыкның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын 14 сәгать 30 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына кертелә торган сорауны расларга: «I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан тыш, Салагыш авыл җирлегенең Салагыш авылында яшәү урыны буенча теркәлгән шулай ук даими рәвештә бер елдан артык яшәүче, балигъ булган һәр халыктан 2020 нче елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Салагыш авылының Тукай урамындагы юлга вак таш сатып алу һәм чокырларны ямау.
2. Салагыш авылындагы йортларга адреслы табличкалар ясау.
3. Су насосы сатып алу .

4.Салагыш авылы урамнарын кардан чистарту.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3.Салагыш авыл җирлеге башкарма комитетына халык җыенын оештыру һәм үткәрүне йөкләргә.

4.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе
Авыл җирлеге башлыгы М. М. Мөхәмәдиев